Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл Советы

КАРАРЫ

№106

12 декабрь 2024 ел

Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 49 нчы номерлы «Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Васильевка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2018 елның 24 август 49 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2018 елның 5 нче декабренә 51 номерлы, 2020 елның 11 нче декабрендә 8 номерлы, 2022 нче елның 14 нче декабренә 62 номерлы, 2024 нче елның 26 нчы июнендәге 98 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Васильевка
авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (12 группа хезмәткә түләү) |
| --- | --- |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 167 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 18 607» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 19 173 |
| Башлык урынбасары | 13 991» |

2. Әлеге карарны Васильевка авылы, Үзәк ур., 26 йорт; Улаклы-Чишмә авылы, Үзәк ур., 32а йортлары территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Васильевка авыл җирлеге башлыгы — Ш.М. Касыймуллин